СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Ташкичү авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **№ 3**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ак-чишма авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 13 ноябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ак-чишма авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында гражданнар җыенының беренче этабын

Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ак-Чишмә авылында Ак-Чишмә авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча 2024 елның 05 апрелендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ак-чишма авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 8 номерлы карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда Ташкичү авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 250 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналаыңр, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Үзәк, Зеленая урамнары);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу);

- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыклары ясау, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка

инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су насосы сатып алу);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 22 ноябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына ТР, Арча районы, Ак-Чишмә авылы, Мәктәп урамы, 5 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ